■ Хәзрәт вәгазе

# ӘХЛАК

"Һәр бинаның нигезе бар. Исламның нигезе – күркәм әхлак".

Ибн Габбас.

Габдрахман КАЙА

### ӘХЛАК НӘРСӘ?

Әхлак - Тумыштан яки укуөйрәнү вә гаилә тәрбиясе белән казанылган рухи хәлләр (хәят) димәктер.

Сүзләрендә, эшләрендә, һәртөрле хәл вә хәрәкәтләрендә дөрес эш иткән кешегә әхлаклы кеше диярләр. Пәйгамбәребез бер хәдисендә түбәндәгечә боерган: "Холкы яхшы булган мөселман - иман ягыннан иң мөкәммәл мөселмандыр".

Дин дә, яхшы әхлак та, кешеләр белән Аллаһы Тәгалә, шулай ук кешенең кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрен билгеле бер тәртипкә сала. Кеше дөньяда башка кешеләр белән аралашып яши. Кайда гына булмасын, бердән артык кеше булган җирдә кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне җайга салучы кануннар, кагыйдәләр, гореф-гадәтләр барлыкка килә. Ислам әхлагы исә дингә таянган һәм көчен, куәтен ислам диненнән алган гүзәл бер әхлактыр.

### ӘХЛАК ВАЗИФАЛАРЫБЫЗ

- Аллаһы Тәгаләгә вә Пәйгамбәребезгә карата булга вазифаларыбыз;
- үзебезгә карата булган вазифаларыбыз;
- гаиләбезгә карата булган вазифаларыбыз;
- Ватан вә милләтебезгә карата булган вазифаларыбыз;
- кешелеккә карата булган вазифаларыбыз.

### АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘГӘ КАРАТА БУЛГАН ВАЗИФАЛАРЫБЫЗ

- Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышану;
- Аллаһ кушкан эшләрне эшләү;
- Аллаһ тыйган эшләрдән тыелу;
- Аллаһ биргән санаусыз нигъмәтләргә шөкрана кылу;
- Аллаһы һәрнәрсәдән өстен күреп, Аллаһы Тәгаләне сөю хисен күңелгә урнаштыру;
- Аллаһны сөюне Аллаһтан куркудан өстен итү;
- Аллаһка чын күңелдән гыйбадәт кылу;
- Аллаһка карата һәрвакыт тәрбияле, әдәпле булу, аның исемен хөрмәт белән телгә алу.

### ПӘЙГАМБӘРЛӘРЕБЕЗГӘ КАРАТА БУЛГАН ВАЗИФАЛАРЫБЫЗ

Кешелекне караңгы бер дөньядан коткарып, якты бер дөнья тәкъдим иткән һәм безгә дөнья вә ахирәт бәхете әзерләгән кеше - Пәйгамбәребез Хәзрәти Мөхәммәдтер. Безнең пәйгамбәребезгә карата булган төрле вазифаларыбыз бар:

- Хәзрәти Мөхәммәднең пәйгамбәрлегенә ышану;
- Пәйгамбәр аңлаткан дини мәсьәләләрнең дөреслеген һәм боларның Аллаһтан килгәнлеген кабул итү;
- аның әхлагы белән яшәү;
- Пәйгамбәребезнең ялгыз бер милләткә генә түгел, бөтен кешелеккә пәйгамбәр буларак җибәрелгәнен кабул итү, аның әмер вә тәүсияләренә өйрәнү, тыйганнарыннан тыелу;
- аның тормышын үзебезгә үрнәк итеп, аның сөннәте буенча яшәү;
- аның исемен ишеткән вакытта, аны "Саллаллаһү галәйһи вә сәлләм" яки "Галәйһиссалатү вәс-сәлам" дип хөрмәт белән искә алу;
- Аллаһ вә Пәйгамбәрне үз җаныбыздан да артык итеп ярату һәм хөрмәт итү.

### ҮЗЕБЕЗГӘ КАРАТА БУЛГАН ВАЗИФАЛАРЫБЫЗ

Аллаһы Тәгалә барлыклар арасында иң өстен затлы кешедер. Кешенең тән һәм бу тәннең эчендә күзгә күренмәгән рухы бар. Ислам дине кешенең тәнен һәртөрле хасталыклардан һәм зарарлы нәрсәләрдән саклый, рухын үстерә. Яхшы кеше булыр өчен ялгыз тән сәламәтлеге генә җитмидер, рух сәламәтлеге дә кирәк.

Пәйгамбәребез бер хәдисендә болай боерган: "Аллаһ сезнең тышкы сурәтләрегезгә карамас. Ләкин Аллаһ сезнең эчегезгә, калебләрегезгә карар". Димәк ки, эчке арулык, рух арулыгы Ислам динендә зур әһәмияткә ия. Шуның өчен дә кешенең үзенә карата булган иң мөһим вазифаларыннан берсе булып үзен рухи яктан үстерү санала. Начар вә пычрак уйлардан үзен саклау, башкалар турында ямьсез фикер йөртүдән үзен тыю кешенең үзенә карата булган иң төп вазифалары булып исәпләнә.

Ислам дине буенча кешегә ике төрле хасталык хас. Аның берсе матди, икенчесе мәгънәви хасталык. Тәнебезгә хас булган матди хасталыклар күзгә күренеп беленә. Гәүдәбезне һәртөрле матди хасталыклардан саклау, шулай ук - үзебезгә карата булган вазифаларыбызның берсе. Мәгънәви хасталыклар күзгә күзгә күренмәсләр. Гайбәт, ялганчылык, яла ягу, хәйләкәрлек, алдау, бөтәннәрне мыскыл итү, көнләү, тәкәбберлек, саранлык вә ялкаулык рухи хасталыклардан санала.

Пәйгамбәребез болай диган: "Ике көнен бертигез үткәргән кеше зарардадыр". Чын мөселман һәр көн алга таба баручы вә өзлексез үзен камилләштерү өстендә эшләүче кешедер. Гыйлемлеккә омтылган, тормышын тырышлык белән алып барган, башкаларның тәҗрибәсен өйрәнгән кеше үзенә дә, милләтенә вә диненә дә файда китерә ала. Аның әйләнә-тирәдәгеләр арасында дәрәҗәсе бар, андый кешенең сүзенә һәркем колак сала. Үзен яхшы тәрбия кылган кеше - үзенә карата булган әхлак вазифаларын үтәгән булып санала.

*Дәвамы икенче номерда.*

## Хәдис шәрифләр

• Изгелек - күркәм холык, гөнаһлылык - халыкка сөйләсәң, халыкны нәфрәтләндерәчәк яманлыкларыңны күңелеңдә бәйләп тоту.

• Изгелек - күңелгә урнашып, җанның анда тынгылык тапкан нәрсәсе, начарлык - киңәшчеләр үгетенә карамастан, күңелгә урнашып та, җанның анда тынгылык таба алмаган нәрсәсе.

• Яхшылык искерми, гөнаһ онытылмый, Аллаһ тәгалә үлми, үзең теләгәнчә гамәл ит. Ничек әҗәткә бирсәң шулай кайтарып алырсың.

• Ачы - бал боза, көнчелек - иман боза.

• Агачны ут ничек ашап бетерә торган булса, кинә белән көнчелек тә изгелекне шулай ашап бетерер.

• Көнләшүче, сүз йөртүче, яки алдагысын хәбәр итүче минем өммәттән түгел, мин дә аларныкы түгел.

• Күркәм холык үлчәүне изгелек ягына басучы. Моның белән күркәм холыкка ия булган кеше руза тотучылар һәм намаз укучылар дәрәҗәсенә ирешкән булыр.

• Кайгыларны, авыртуларны, сәдакаларны яшерү - изгелек диган хәзинәдән.

• Хәләл ризык тапканда арып-талып йокларга ятучылар шул төнне гөнаһсыз узды-рылар.

• Кем җаны бугазына җиткәнче тәүбәгә килә, шуның тәүбәсен Аллаһ тәгалә кабул итә.

• Кем Аллаһга тыйнаклыкта, шуны Аллаһ тәгалә дәрәҗәгә күтәрә.

• Мөселман кеше өчен хакимлек итүдә изгелек юк.

• Эшләрен күркәм итеп башкаручыларны Аллаһ тәгалә сөяр.

## Өфөлә намаҙ ваҡыты

**Рабигел әүүәл 2011 миләди йыл**
**1432 һижри йыл.**

| Рабигәл әүүәл | Аҙна көндәре | Февраль Март | Иртәнге намаҙ | Ҡояш сыға | Өйлә нам. | Икен. нам. | Аҡшам. | Йәстү намаҙы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16 | Шәмбе | 19 | 7.02 | 8.32 | 13.30 | 16.58 | 18.28 | 19.58 |
| 17 | Йәкшәмбе | 20 | 7.00 | 8.30 | 13.30 | 17.00 | 18.30 | 20.00 |
| 18 | Дүшәмбе | 21 | 6.57 | 8.27 | 13.30 | 17.02 | 18.32 | 20.02 |
| 19 | Шишәмбе | 22 | 6.55 | 8.25 | 13.30 | 17.05 | 18.35 | 20.05 |
| 20 | Шаршамбы | 23 | 6.53 | 8.23 | 13.30 | 17.07 | 18.37 | 20.07 |
| 21 | Кесе йома | 24 | 5.50 | 8.20 | 13.30 | 17.09 | 18.39 | 20.09 |
| 22 | Йома | 25 | 6.48 | 8.18 | 13.30 | 17.11 | 18.41 | 20.11 |
| 23 | Шәмбе | 26 | 6.46 | 8.16 | 13.30 | 17.13 | 18.43 | 20.13 |
| 24 | Йәкшәмбе | 27 | 6.43 | 8.13 | 13.30 | 17.15 | 18.45 | 20.15 |
| 25 | Дүшәмбе | 28 | 6.41 | 8.11 | 13.30 | 17.17 | 18.47 | 20.17 |
| 26 | Шишәмбе | 1 | 6.39 | 8.09 | 13.30 | 17.19 | 18.49 | 20.19 |
| 27 | Шаршамбы | 2 | 6.36 | 8.06 | 13.30 | 17.21 | 18.51 | 20.21 |
| 28 | Кесе йома | 3 | 6.34 | 8.04 | 13.30 | 17.23 | 18.53 | 20.23 |
| 29 | Йома | 4 | 6.31 | 8.01 | 13.30 | 17.25 | 18.55 | 20.25 |
| 30 | Шәмбе | 5 | 6.29 | 7.59 | 13.30 | 17.27 | 18.57 | 20.27 |
| 1 | Йәкшәмбе | 6 | 6.27 | 7.57 | 13.30 | 17.29 | 18.59 | 20.29 |
| 2 | Дүшәмбе | 7 | 6.24 | 7.54 | 13.30 | 17.31 | 19.01 | 20.31 |
| 3 | Шишәмбе | 8 | 6.22 | 7.52 | 13.30 | 17.33 | 19.03 | 20.33 |
| 4 | Шаршамбы | 9 | 6.19 | 7.49 | 13.30 | 17.35 | 19.05 | 20.35 |
| 5 | Кесе йома | 10 | 6.17 | 7.47 | 13.30 | 17.37 | 19.07 | 20.37 |
| 6 | Йома | 11 | 6.14 | 7.44 | 13.30 | 17.39 | 19.09 | 20.39 |
| 7 | Шәмбе | 12 | 6.12 | 7.42 | 13.30 | 17.41 | 19.11 | 20.41 |
| 8 | Йәкшәмбе | 13 | 6.09 | 7.39 | 13.30 | 17.43 | 19.13 | 20.43 |
| 9 | Дүшәмбе | 14 | 6.07 | 7.37 | 13.30 | 17.45 | 19.15 | 20.45 |
| 10 | Шишәмбе | 15 | 6.04 | 7.34 | 13.30 | 17.47 | 19.17 | 20.47 |
| 11 | Шаршамбы | 16 | 6.02 | 7.32 | 13.30 | 17.49 | 19.19 | 20.49 |
| 12 | Кесе йома | 17 | 5.59 | 7.29 | 13.30 | 17.51 | 19.21 | 20.51 |
| 13 | Йома | 18 | 5.57 | 7.27 | 13.30 | 17.53 | 19.23 | 20.53 |
| 14 | Шәмбе | 19 | 5.54 | 7.24 | 13.30 | 17.55 | 19.25 | 20.55 |
| 15 | Йәкшәмбе | 20 | 5.52 | 7.22 | 13.30 | 17.56 | 19.26 | 20.56 |

■ Сәламәтлек

## Аз ашауның өстенлекләре

***Динебез тукланганда чама белуне таләп итә. Моның табигый сәбәпләре бик күп. Шуларның берничәсен карап үтик:***

1. Күп ашамаучының йөрәге чиста, саф була. Нык туйган тамак йөрәкне томалый, яшәү сәләтен, фикерләү дәрәҗәсен киметә.
2. Ач кешенең йөрәге нечкә һәм хисчән буладыр. Ул гыйбадәт кылуның тәмен ныграк тоя.
3. Ачлык адәм баласына бик тә хас булган тәкәбберлекне юкка чыгара ала.
4. Аз ашаучы кеше тыныч була, аның гыйбадәт кылырга, гыйлем алырга вакыты күбрәк кала.
5. Нык туенырга яратучы кеше үз хәсәтлегенең колы була башлый.
6. Ач тамаклы кеше күп йокламас. Күп йоклау - начар гадәтләрдәндер.
7. Ашказаны гел ризык белән тулган кеше мескеннәр хакында һәм ахирәт турында да онытыр.
8. Аз ашаган кешенең сәламәтлеге ныграк булыр.
9. Аз ашаучы кешенең матди чыгымнары да азрак.



## ГАРИП ТӨЛКЕ ҺӘМ АРЫСЛАН

Шәех САДИ

Бер кеше төнне тынычсыз бер кырда үткәрергә мәҗбүр була. Ерткыч хайваннардан сакланып, бер зур агачка менеп утыра. Күп вакыт та үтми, бер гарип төлке килеп, шул агач астына сузылып ята. Агачтагы кеше: "Бу мескен төлке нәрсә ашап-эчеп көн күрә икән?" - дип уйлап куя. Бервакыт ерактан бер арысланның килгәнен күрә. Арыслан авызына болан капкан. Төлке, арысланны күргә, яшерәнә. Арыслан нәкъ шул агачның астына килеп, табышын ашый. Туйганчы ашаганнан соң, ризыгының бер өлешен калдырып китә. Шунда төлке, яшеренгән урыныннан чыгып, авыр аксап килә дә, арысланнан артып калган боланны ашап туена.

Агачтагы кеше исә: "Димәк, гарип, хаста бер хайванның да ризыгын Аллаһ аның янына китерә һәм аны ач калдырмый икән. Шулай булгач, нигә мин көне-төне тырышып, арыганчы эшләп йөрим соң, Моннан ары мин дә төлке шикелле бер эш эшләмичә, ризыгымны көтеп кенә алырмын", - дип уйлый.

Икенче көнне иртүк юл кырыендагы бер өнгә карап ризыгын көтә башлый. Бер көн, ике көн, өч көн көтә.

Ләкин беркем дә килеп ризык китерми. Ачлыкка түзә алмыйча, аңын югалтып егыла.шулвакыт бер төш күрә һәм төшендә берәү аңа болай ди: "Әй, юләр, әй, ахмак кеше, ялкауланма! Нигә ятып торасың? Тор, тәнең сәламәт чагында эшлә, ялкауланма. Нигә үзеңне гарип төлке урынына куясың, Арыслан шикелле бул да, синең табышыңнан артыгын башкалар файдалансын!"